## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ (КАРАР)

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Балтач шәһәр тибындагы поселогы**

18 декабрь 2023ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең Балтач шәһәр тибындагы поселогында гражданнар җыены карар итте:

1. Балтач шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган баладан 2024 елда, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзәләреннән кала 500 сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Балтач шәһәр тибындагы поселогында: Р.Фазлыев урамы буенча бетон өслекле җәяүлеләр тротуары урнаштыру.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Балтач муниципаль районы

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин